РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МӨСЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**К А Р А Р № _09___**

Мөслим авылы «_03__» _июля__2023 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» 2017 елның 15 февралендәге 3 номерлы Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы буенча Федераль монополиягә каршы хезмәт идарәсенең 2023 елның 19 маендагы кисәтүен карау нәтиҗәләре буенча, Мөслим авыл җирлегенең Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү тәртибе кушымтасына, 4 өлешен яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Аукционда стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына килешү төзүгә дәгъва кылучы оештыру-хокукый формасына, милек формасына, урнашу урынына, шәхси эшмәкәр яки үзмәшгуль һөнәри керемгә салым түләүче теләсә кайсы юридик зат катнаша ала (алга таба – урнаштыру килешүе)»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Мөслим муниципаль районы, Пушкин ур. 43 нче йорт, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгыгымда калдырам.

Мөслим авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе М.А.Байрханов